# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"1995 елга Татарстан Республикасының
бюджет системасы турында"

1 статья. 1995 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын чыгымнар буенча - 2993495 млн.сум күләмендә һәм керемнәр буенча 2717422 млн.сум күләмендә дип билгеләргә.

1995 елга Татарстан Республикасының республилка бюджеты кытлыгының иң зур чиген 276073 млн.сум яисә 1995 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты чыгымнарына карата 9 процент дип билгеләргә.

2 статья. 1995 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәре өстәлгән бәяләргә салым, акцизлар, халык хуҗалыгының мөһим тармакларына финанс ярдәме күрсәтү өчен предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан махсус салым, кыйммәтле кәгазьләр белән башкарылучы гамәлләрдән салым, предприятиеләрдән һәм оешмалардан табышка салымның бер өлеше, физик затлардан керем салымының бер өлеше, башка керемнәр һәм җыемнар исәбенә барлыкка килә дип билгеләргә.

3 статья. "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнгән җир өчен салым ставкаларын 1995 елда шәһәр һәм поселок җирләре өчен 1995 елның 1 гыйнварында гамәлдә булган ставкаларга карата 2 коэффициенты белән кулланырга дип билгеләргә.

4 статья. "1994 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законының 8,9,17 һәм 18 статьяларының гамәлдә булуын 1995 елга озынайтырга.

5 статья. Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче табышка салым ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

а) предприятиеләр, оешмалар һәм чит ил хокукый затлары өчен - 22 процент күләмендә;

б) биржалар, брокер конторалары, кредит һәм иминләштерү оешмалары, предприятиеләр өчен - арадашчы гамәлләреннән һәм килешүләрдән алынган табыш буенча - 30 процент күләмендә.

6 статья. Керемнәргә салымнар буенча түбәндәге ставкалар билгеләргә:

а) предприятиеләр һәм оешмалар карамагындагы акцияләр, облигацияләр һәм чыгарылган башка кыйммәтле кәгазьләр буенча алынган дивидендлардан, процентлардан (моңа дәүләт облигацияләреннән һәм башка кыйммәтле дәүләт кәгазьләреннән алынган керемнәр керми) - 2 процент күләмендә, ә кредит оешмаларының күрсәтелгән керемнәренә - 5 процент күләмендә;

б) видеосалоннардан (видеокүрсәтүләрдән), видео һәм аудиокассеталар прокатыннан, шулай ук аларга яздырулардан - 57 процент күләмендә;

в) казинолардан, башка уен йортларыннан (урыннарыннан) һәм башка уен бизнесыннан - 77 процент күләмендә.

7 статья. Су хуҗалыгы системасыннан сәнәгать предприятиеләре ала торган су өчен 1994 елның 31 декабренә гамәлдә булган түләүләр 2,3 коэффициенты белән кулланыла дип билгеләргә.

8 статья. Предприятиеләрнең мөлкәтенә салым буенча ставкаларны салым салу базасының 2 проценты күләмендә дип билгеләргә.

9 статья. Физик затларның мөлкәтенә салым (корылмалар, биналар, төзелмәләр) ставкаларын алар карамагындагы мөлкәт хакының 0,1 проценты күләмендә дип билгеләргә.

10 статья. Дәүләт мөлкәтен һәм җирле мөлкәтне хосусыйлаштырудан килгән акчалар, реинвестицияләүгә җибәрүне исәпкә алып, төрле дәрәҗәдәге бюджетлар һәм хосусыйлаштыру фондлары арасында түбәндәге нормативлар буенча бүленә:

а) фондлар һәм бюджет арасында:

(процентларда)

| | хосусыйлаштыру фондларына | Татарстан Республикасы бюджетына |
|---|---|---|
| Хосусыйлаштырудан килгән гомуми сумма | 10 | 90 |

б) төрле дәрәҗәдәге бюджетлар арасында:

(процентларда)

| Хосусыйлаштыру объектларыннан | Татарстан Республикасының республика бюджетына | җирле бюджетларга |
|---|---|---|
| республика милкен | 70 | 30 |
| җирле милекне | 30 | 70 |

11 статья. Сәнәгать тибындагы технологияләр буенча авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүче индустрия тибындагы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең түбәндәге исемлеген расларга:

а) кошчылык фабрикалары, кошчылык совхозлары, кошчылык буенча "Татарстан" җитештерү берләшмәсенең нәсел репродукторлары;

б) җәнлек үрчетү буенча "Татпушнина" җитештерү берләшмәсенең җәнлек совхозлары;

в) эре терлекчелек комплекслары һәм теплица хуҗалыклары:

- Зеленодол районының "Майский" совхозы;
- Тукай районының "Весенний" һәм "Сосновоборский" совхозлары;
- Бөгелмә районының "Пугачевский" совхозы.

129



12 статья. 1995 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында төп чыганаклар буенча керемнәрнең килерен түбәндәге суммаларда дип исәпкә алырга:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| Өстәлгән бәяләргә салым | 620000 |
| Акцизлар | 741300 |
| Предприятиеләр һәм оешмалар табышына салым | 332068 |
| Предприятиеләр милкәтенә салым | 25418 |
| Физик затлардан керем салымы | 75944 |
| Дәүләт пошлинасы | 5382 |
| Хосусыйлаштырудан керемнәр | 122699 |
| Тышкы икътисадый эшчәнлектән керемнәр | 200000 |
| Җир асты байлыклары өчен түләү | 105625 |
| Җир өчен салым | 29028 |
| Башка салымнар, җыемнар һәм башка килерләр | 184098 |
| Халык хуҗалыгының мөһим тармакларына финанс ярдәме күрсәтү өчен предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан махсус салым | 111900 |

130

| | |
|---|---|
| Кыйммәтле кәгазьләр белән башкарылучы гамәлләрдән салым | 12000 |
| Түбәнгерәк бюджетлардан алынырга тиешле акчалар | 151960 |

13 статья. 1995 елда предприятиеләрдән мөлкәткә салым һәм физик затлар мөлкәтенә салым тулысынча районнар һәм шәһәрләр бюджетларына күчереләчәк дип билгеләргә.

14 статья. 1995 елда предприятиеләрдән һәм оешмалардан табышка салымны һәм физик затлардан керем салымын Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм районнарның, шәһәрләрнең бюджетларына күчерү нормативын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

(процентларда)

| NN тн | Районнарның һәм шәһәрләрнең исемнәре | Предприятиеләр һәм оешмалар табышына салым (салым салынучы табыштан ставка 22%) | | Физик затлардан керем салымы (11% лы ставка буенча керүче салым контингентыннан процентларда) | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | районнар һәм шәһәрләр бюджетларына | республика бюджетына | районнар һәм шәһәрләр бюджетларына | республика бюджетына |
| 1. | Алабуга районы | 22 | - | 100 | - |
| 2. | Азнакай - " - | 15 | 7 | 100 | - |
| 3. | Алексеевск - " - | 22 | - | 100 | - |
| 4. | Аксубай - " - | 22 | - | 100 | - |
| 5. | Актаныш - " - | 22 | - | 100 | - |
| 6. | Апас - " - | 22 | - | 100 | - |
| 7. | Арча - " - | 22 | - | 100 | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8. | Баулы - " - | 22 | - | 100 | - |
| 9. | Балтач - " - | 22 | - | 100 | - |
| 10. | Буа - " - | 22 | - | 100 | - |
| 11. | Биек Тау - " - | 22 | - | 100 | - |
| 12. | Балык Бистәсе - " - | 22 | - | 100 | - |
| 13. | Бөгелмә - " - | 14 | 8 | 100 | - |
| 14. | Зеленодол - " - | 22 | - | 100 | - |
| 15. | Зәй - " - | 22 | - | 100 | - |
| 16. | Кайбыч - " - | 22 | - | 100 | - |
| 17. | Кама Тамагы - " - | 22 | - | 100 | - |
| 18. | Кукмара - " - | 22 | - | 100 | - |
| 19. | Лаеш - " - | 22 | - | 100 | - |
| 20. | Лениногорск - " - | 22 | - | 100 | - |
| 21. | Мамадыш - " - | 22 | - | 100 | - |
| 22. | Менделеевск - " - | 22 | - | 100 | - |
| 23. | Минзәлә - " - | 22 | - | 100 | - |
| 24. | Мөслим - " - | 22 | - | 100 | - |
| 25. | Октябрь - " - | 22 | - | 100 | - |
| 26. | Питрәч - " - | 22 | - | 100 | - |
| 27. | Саба - " - | 22 | - | 100 | - |
| 28. | Сарман - " - | 8 | 14 | 100 | - |
| 29. | Спас - " - | 22 | - | 100 | - |
| 30. | Теләче - " - | 22 | - | 100 | - |
| 31. | Тукай - " - | 10 | 12 | 40 | 60 |
| 32. | Тәтеш - " - | 22 | - | 100 | - |
| 33. | Түбән Кама - " - | 22 | - | 100 | - |
| 34. | Чирмешән - " - | 22 | - | 100 | - |
| 35. | Чүпрәле - " - | 22 | - | 100 | - |
| 36. | Чистай - " - | 22 | - | 100 | - |
| 37. | Ютазы - " - | 22 | - | 100 | - |
| 38. | Югары Ослан - " - | 22 | - | 100 | - |
| 39. | Яңа Чишмә - " - | 22 | - | 100 | - |
| 40. | Әгерҗе - " - | 22 | - | 100 | - |
| 41. | Әлки - " - | 22 | - | 100 | - |
| 42. | Әлмәт - " - | 5 | 17 | 10 | 90 |
| 43. | Әтнә - " - | 22 | - | 100 | - |
| 44. | Азнакай шәһәре | 22 | - | 100 | - |
| 45. | Әлмәт шәһәре | 8 | 14 | 40 | 60 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 46. | Бөгелмә шәһәре | 10 | 12 | 85 | 15 |
| 47. | Алабуга шәһәре | 22 | - | 100 | - |
| 48. | Зеленодол шәһәре | 22 | - | 100 | - |
| 49. | Лениногорск шәһәре | 21 | 1 | 97 | 3 |
| 50. | Чаллы шәһәре | 15 | 7 | 100 | - |
| 51. | Түбән Кама шәһәре | 8 | 14 | 60 | 40 |
| 52. | Чистай шәһәре | 22 | - | 100 | - |
| 53. | Казан шәһәре | 22 | - | 100 | - |

15 статья. 1995 елның республика бюджетында агымдагы чыгымнарны финанслау өчен ассигнованиеләрнең гомуми күләмен - 2392449 млн.сум дип, үсеш бюджетын финанслау өчен, капитал салуларны да кертеп, 601046 млн.сум дип билгеләргә.

16 статья. 1995 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан 2993495 млн.сум күләмендә ассигнованиеләрне түбәндәге максатларга юнәлтергә:

(млн.сумнарда)

| | Барысы | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|
| | | агымдагы чыгымнар бюджеты | үсеш бюджеты |
| **I. Халык хуҗалыгы** | | | |
| Проектлау эшләренә | 200 | - | 200 |
| Торак-коммуналь хуҗалыгына | 39750 | 39750 | - |
| Автомобиль транспортына | 52027 | 52027 | - |
| "Таттөзелешгазлаштыру" РГПП | 19200 | 19200 | - |
| Халыкка сатыла торган ягулыкка дотациягә | 1517 | 1517 | - |
| Горький тимер юлының Казан бүлегенә | 19400 | 19400 | - |
| "Татфлот" суднолар йөрешле компаниясенә | 7900 | 7900 | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Чаллы шәһәренең елга портына | 900 | 900 | - |
| "Татарстан һава юллары" авиакомпаниясенә | 4400 | 4400 | - |
| "Фармация" сәламәтлек саклауның хуҗалык органнарына | 7500 | 7500 | - |
| Авыл хуҗалыгына | 537425 | 413577 | 123848 |
| Ветеринариянең баш идарәсенә | 8953 | 8053 | 900 |
| Тапшырылган терлекчелек продукциясенә дотациягә | 152000 | 152000 | - |
| Урман хуҗалыгына | 49000 | 41500 | 7500 |
| Ипигә һәм суганга дотациягә | 14700 | 14700 | - |
| Кинематографиягә | 11800 | 11800 | - |
| ТТК өчен торак йортлар түләгешенең бәясе үсешен компенсацияләүгә | 1500 | 1500 | - |
| Яңа тапшырылучы ведомство торак фондын һәм җәмгыяви-мәдәни өлкә объектларын тотуга | 114639 | 114639 | - |
| Табигатьне саклау гамәлләрен финанслауга | 35000 | 1752 | 33248 |
| Җир өчен салым исәбеннән чыгымнарга | 29028 | - | 29028 |
| Кайтарып бирү шарты белән түбәндәгеләр өчен бирелә торган акча: | | | |
| - азык-төлек бодае сатып алуга | 90000 | 90000 | - |
| - авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу өчен республика азык-төлек фондына | 69000 | 69000 | - |
| <u>Халык хуҗалыгын финанслау өчен - барысы</u> | 1265839 | 1069615 | 196224 |

134

П. Җәмгыяви-мәдәни өлкә

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мәгарифкә | 76348 | 76348 | - |
| Мәдәнияткә | 28407 | 28407 | - |
| "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча гамәлләргә | 4000 | 4000 | - |
| Көндәлек матбугатка һәм нәшриятларга | 12500 | 12500 | - |
| Телевидение һәм радиотапшыруларга | 9900 | 9900 | - |
| Сәламәтлек саклауга | 186502 | 186502 | - |
| Физик тәрбия һәм спортка | 12000 | 12000 | - |
| Санэпид күзәтү буенча дәүләт комитетына | 23700 | 23700 | - |
| Яшьләр сәяте өлкәсендәге гамәлләрне финанслауга | 5528 | 5528 | - |
| Җәмгыяви тәэминатка | 23500 | 23500 | - |
| Җәмгыяви-мәдәни өлкә буенча барысы | 382385 | 382385 | - |
| Фәнгә | 11200 | 11200 | - |
| Җәмгыяви яклау гамәлләренә | 80500 | 80500 | - |
| Хакимиятнең вәкиллекле һәм башкарма органнарына | 59735 | 59735 | - |
| Башка чыгымнарга | 217942 | 217942 | - |
| Капитал салулар | 404822 | - | 404822 |
| Түбәнгерәк бюджетларга дотацияләргә | 560538 | 560538 | - |
| Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең резерв фондына | 10534 | 10534 | - |

17 статья. 1995 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советын, хакимиятнең башкарма һәм хөкем органнарын тоту өчен чыгымнарны 59735 млн.сум күләмендә расларга, шул исәптән:

(млн.сум)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, аның Президиумына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратына | 7686 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларына депутат вәкаләтләрен башкару белән бәйле чыгымнарын кайтару өчен | 90 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрен уздыру белән бәйле чыгымнарга | 100 |
| Сайлаулар уздыруга, шул исәптән Үзәк сайлау комиссиясенә - 93 | 3000 |
| Татарстан Республикасы Президентының һәм Президент аппаратының эшчәнлеген финанслау өчен чыгымнарга | 3847 |
| Татарстан Республикасының Конституция күзәтүе комитетына | 133 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитетына | 656 |
| Татарстан Республикасы Президентының Эшләр буенча идарәсе каршындагы кунак йортына | 754 |
| Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына | 6122 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы министрлыкларына, ведомстволарына һәм аларның органнарына | 34013 |
| Татарстан Республикасының даими вәкиллекләренә | 2119 |
| Татарстан Республикасының Югары арбитраж судына | 1215 |

18 статья. "Дәүләт хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3 пунктының ял итү урынына бару һәм аннан кире кайту хакларын түләүгә бәйле өлешендәге, 13 статьяның 8, 11, 12 пунктларындагы, 15 һәм 16 статьялардагы, 17 статьяның 3 өлешендәге, 23 статьядагы чыгымнар 1995 елда финансланмый дип билгеләргә, дәүләт хезмәткәрләренә элек кабул ителгән законнар нигезендә хезмәт өчен түләү, матди һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү белән бәйле чыгымнар моңа керми.

19 статья. Бюджет тарафыннан каралган гамәлләрнең эзлекле финанслануын тәэмин итү йөзеннән, 1995 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан районнар һәм шәһәрләр бюджетынларына 560538 млн.сум күләмендә дотация бүлеп бирергә, шул исәптән:

| | |
|---|---|
| Аксубай районы | 13178 |
| Актаныш районы | 17890 |
| Алексеевск районы | 10563 |
| Апас районы | 9459 |
| Алабуга районы | 8324 |
| Арча районы | 12903 |
| Балтач районы | 12874 |
| Баулы районы | 11827 |
| Балык Бистәсе районы | 11055 |
| Биектау районы | 4907 |
| Буа районы | 11067 |
| Зеленодол районы | 4578 |
| Зәй районы | 6914 |

| | |
|---|---|
| Кайбыч районы | 6787 |
| Кама Тамагы районы | 8062 |
| Кукмара районы | 10951 |
| Лаеш районы | 5392 |
| Лениногорск районы | 1840 |
| Мамадыш районы | 15304 |
| Менделеевск районы | 16434 |
| Минзәлә районы | 722 |
| Мөслим районы | 11426 |
| Октябрь районы | 8775 |
| Питрәч районы | 8051 |
| Саба районы | 10431 |
| Спас районы | 14571 |
| Теләче районы | 5636 |
| Тәтеш районы | 9666 |
| Түбән Кама районы, шул исәптән | 31068 |
| Кама Аланы эшчеләр поселогы | 24279 |
| Чирмешән районы | 5848 |
| Чистай районы | 4142 |
| Чүпрәле районы | 11515 |
| Югары Ослан районы | 7517 |
| Ютазы районы | 523 |
| Яңа Чишмә районы | 7058 |
| Әгерҗе районы | 8724 |
| Әлки районы | 11964 |
| Әтнә районы | 5755 |
| Әлмәт шәһәре | 16562 |
| Алабуга шәһәре | 12031 |
| Зеленодол шәһәре | 10386 |
| Чистай шәһәре | 4289 |
| Казан шәһәре | 153569 |

20 статья. Татарстан Республикасының республика бюджеты касса әйләнешенең гамәлдәге акчаларын 1996 елның 1 гыйнварена 12 млрд.сум күләмендә расларга.

21 статья. 1995 елда Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты башкарма хакимиятнең республика органнары хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тиеш.

22 статья. 1995 елга Татарстан Республикасы республика бюджетының тулы күләмдә финансланырга тиешле яклануы агымдагы чыгымнарының түбәндәге исемлеген расларга: Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына, җәмгыяви иминлек кертемнәрен һәм түләүләрен дә исәпкә алып, хезмәт хакы; стипендияләр; дәүләт пособиеләре, башка җәмгыяви түләүләр һәм халыкка компенсация түләүләре; җәмәгать тукльнуы; медикаментлар һәм яраларны бәйләү чаралары сатып алу; хезмәт хакы түләү өчен җирле бюджетка җибәрелүче дотацияләр.

23 статья. Татарстан Республикасының 1995 елга республика бюджетының өстәмә әлеге Законның 1 статьясында билгеләнгән суммадан күбрәк алынучы керемнәре әлеге Законның 16 статьясында каралган чыгымнарны шушы статьяда ук билгеләнгән чагыштырмаларда арттыру өчен юнәлтелә дип билгеләргә.

24 статья. Әлеге Законны кабул ителгән көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 27 апреле
N 59

Зольна/6